ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г. Казань Боерык

31.08.2021 № 258- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 елдан 346-од номерлы боерыгы белән расланган, региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максаты белән боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 елдан 346-од номерлы боерыгы белән расланган, региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон

таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга. (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 04.06.20021 ел, 164-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән).

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф.С.Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетының
31.08.2021 ел 258-од
номерлы боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 елдан 346-од номерлы боерыгы белән расланган, региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр:

«2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы.

Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазен җибәрү.

2.2. Башкарма хакимият органы исеме.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау.

1) Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазен җибәрү (алга таба – туры килү турында белдерү кәгазе) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

2) Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), төзелгән яки үзгәртеп корылган

индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәү турында белдерү кәгазен җибәрү (алга таба – туры килмәү турында белдерү кәгазе) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

3) Белдерү кәгазен карап тикшермичә генә кире кайтару.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты.

Туры килү (туры килмәү) турындагы белдерү кәгазен җибәрү процедурасын гамәлгә ашыру вакыты, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү тәмамлануы турында хәбәр килгән көннән җиде эш көне тәшкил итә (алга таба - төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе).

Белдерү кәгазен карап тикшермичә кайтару, төзелеш тәмамлануы турында хәбәр килгән көннән өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә гариза һәм кушып бирелә торган документларны Комитетка тапшыру, Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тәэмин ителә. Төзелеш тәмамлануы турында белдерү кәгазен җибәрү яки кире кайтару процедурасын гамәлгә ашыру вакытында, гаризаның КФҮтә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Комитеттан КФҮкә тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге,гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе.

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 19 сентябрендәге «Индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектларын төзү һәм реконструкцияләү өчен кирәкле белдерү кәгазе формаларын раслау турында» 591/пр номерлы боерыгы (алга таба - Россия Төзелеш Министрлыгының № 591/пр боерыгы) белән расланган форма буенча төзелешне тәмамлау турында белдерү кәгазен җибәрү (әлеге Регламентка 1 нче кушымта).

Төзелеш тәмамлануы турындагы белдерү кәгазенә түбәндәге документлар теркәлә:

1) белдерү кәгазе төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән очракта, төзүченең вәкаләтен раслый торган документ;

2) төзүче чит ил юридик заты булган очракта, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларының рус теленә таныкланган тәрҗемәсе;

3) индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының техник планы;

4) шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты төзелгән яки реконструкцияләнгән җир кишәрлеге гомуми өлешле милек хокукында ике һәм аннан да күбрәк гражданга яки арендатор ягында арендага алу хокукында күп кенә затлар караган очракта, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортына, җир кишәрлегенә ия булучылар арасында гомуми өлешле милек хокукында аларның өлешен билгеләү турында төзелгән килешү.

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушылып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып җибәрелергә мөмкин:

1) Комитетка шәхсән яисә почта аша кәгазь иядә һәм «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

2) КФҮ аша кәгазь иядә һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

Гариза биргәндә мөрәҗәгать итүчегә КФҮтән гариза җибәрелүен раслаучы теркәү номеры һәм электрон гариза бирү датасы белән расписка бирелә;

3) Республика порталы аша электрон формада.

Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелеп, гаризаның җибәрелгәне турында белдермә килә.

Гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гариза гади электрон имза белән имзалана.

Мөрәҗәгать итүчегә, гади электрон имза алу өчен, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба - ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алуны стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Запросны республика порталы аша биргәндә гариза бирүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры

китереп, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларны электрон рәвештә тапшыра.

2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларда булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы, норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысулларын, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе;

Бу категориягә караган документларны тапшыру таләп ителми.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документлар тапшырмау;

2) документларда килешенмәгән чистартулар, өстәмә язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.

3) документларны тиешле булмаган органга бирү;

4) гариза һәм башка документлар электрон култамганы кулланып, гамәлдәге законнарны бозып имзаланган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1. Туры килмәү турында белдерү кәгазе җибәрү өчен нигезләр:

а) төзелгән яисә үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектларның параметрлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының ( алга таба - РФ ШтК ) 55 статьясындагы 19 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән, җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары төзелеше кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының, башка федераль законнар белән билгеләнгән чик параметрларына туры килмәве, яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры килмәве;

б) индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәте, планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә кушымта булып торучы яки планлаштырыла торган төзелеш турында белдерүдә күрсәтелгән типлаштырылган архитектура карарына мондый объектның яки йортның тышкы кыяфәте тасвирламасына туры килмәве яки төзүчегә җибәрелгән белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектының, планлаштырыла торган параметрлары турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларына туры килмәве һәм (яки) федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү очрагында, РФ ШтК $51^1$ статьясының 10

өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән нигез буенча, шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга рөхсәт ителмәве;

в) төзелгән яки үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән файдалану төре, индивидуаль торак төзелеше объектыннан яки бакча йортыннан рөхсәт ителгән файдалану төре планлаштырыла торган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән рөхсәт төренә туры килмәве;

г) капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата кабул ителгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карарда күрсәтелгән чикләүләр каралган очраклардан тыш һәм мондый капиталь төзелеш объекты эксплуатациягә кертелмәгән очракта, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә төзелеш тәмамлану турындагы белдерү кәгазендә кергән көнгә билгеләнгән чикләүләргә туры килмәве;

2. белдерү кәгазен карап тикшермичә кайтару өчен нигезләр:

а) төзелеш тәмамлануы турындагы белдерү кәгазендә түбәндәге белешмәләрнең булмавы:

төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары (физик зат өчен);

төзүче (юридик зат өчен) атамасы һәм урнашу урыны, шулай ук юридик затның бердәм дәүләт регистрациясе турындагы язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очрактан тыш;

җир кишәрлегенең кадастр номеры (булса), җир кишәрлегенең адресы яки тасвирламасы;

төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның хокуклары турында белешмәләр (андый затлар булганда);

җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан (индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектыннан)рөхсәт ителгән файдалану рәвеше турында белешмәләр;

шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен билгеләнмәгәнлеге турында мәгълүмат;

төзүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;

төзелгән яки үзгәртеп корылган шәхси торак төзү яки бакча йорты объектының параметры турында;

хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган өчен дәүләт пошлинасын түләү турында;

төзүчегә хәбәр җибәрү ысулы турында;

б) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар беркетелмәү;

в) аның нигезендә индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү гамәлгә ашырылган, төзелеш тәмамлануы турында белдерү кәгазе планлаштырылган төзелеш турында хәбәр алынганнан соң ун ел үткәннән соң килүе, яки мондый индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортын

төзү планлаштырыла торган төзелеш объектын яисә бакча йортын төзү турында белдерү кәгазе элек җибәрелмәгән булса (шул исәптән төзүчегә әлеге Кодексның 51[1] статьясындагы 6 өлеше нигезендә кире кайтарылган булса).

Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән очракларда, төзелеш тәмамлану турында белдерү һәм аңа кушып бирелгән документлар мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла, һәм белдерү кәгазе җибәрелмәгән дип санала.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап алганда һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты:

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.

Аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада да, запросны теркәү вакыты һәм тәртибе.

Гариза кергән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән соратып алу ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә.

Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан КФҮ аша бирелгән гариза КФҮтән кергән көнне Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Электрон рәвештә кергән гариза, Региональ порталда запросларны автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә. КФҮтә гариза биргән очракта, гариза бирү датасы булып, Комитетта гаризаны теркәү көне санала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү

системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә алып барыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм ярдәмче этләр белән йөрүчеләргә, бинадан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла, алар арасында:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;

Комитет территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Комитет бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыга, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга биналарда ярдәм күрсәтү;

инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, биналарга һәм хезмәт алуга тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешле урында урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-ноктал шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертергә рөхсәт бирү;

ярдәмче этнең махсус укуын раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Ярдәмче этнең махсус укуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма һәм тәртиптә бирелә торган документ булган очракта, ярдәмче этне кертү рөхсәт ителә;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан, инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулаучы киртәләрне үтәргә ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның керү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр, 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, реконструкция, модернизация узган объектларга карата кулланыла.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге , башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә мөрәҗәгать итүчене сайлау буенча (экстерриториаль принцип), Федераль законның 15.[1] статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратып алу юлы белән (комплексны запрос )

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең уңайлылык күрсәткечләре:

биналарның җәмәгать транспортына якын урнашуы;

кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеlә торган бүлмәләр булу;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

документларны кабул итә торган бүлмәләргә инвалидларның керү мөмкинлеге булуы;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы башка киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

Комитет белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Комитет белгечләре белән хезмәттәшлеге саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан - туры-икедән дә артырга тиеш түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар җибәргәндә, почта аша, шул исәптән электрон почта аша - бердән артырга тиеш түгел.

КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәткәндә документларны кабул итү һәм бирү эшен КФҮ белгече башкара.

Мөрәҗәгать итүче КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәгәннән соң, бер эш көне эчендә Комитетка гариза һәм документларны тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет һәм КФҮ арасындагы хезмәттәшлек килешү нигезендә, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр арасында аралашу-КФҮ эше Регламенты белән җайга салына

Дәүләт хезмәте экстриториаль принцип буенча яки комплексцы соратып алу составында күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Комитетта, Республика порталының шәхси кабинетында , КФҮтә алырга мөмкин.

2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре

Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Республика порталыннан файдаланып,дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул

исәптән, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7 [2] пункты нигезендә, электрон рәвешләре элегрәк танылканган документлар һәм мәгълүмат бирергә;

в) электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмә алырга;

г) электрон документ формасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга;

д) Республика порталы, Федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша, Комитетның карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аның вазыйфаи затларына, дәүләт хезмәткәрләренә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итә торган шикаять бирергә.

Гаризаны тутыру Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Башка формада тапшыру таләп ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе, әгәр бу Республика порталы аша җибәрелгән гаризада күрсәтелсә, Республика порталы аша, электрон култамга белән имзаланып, электрон документ рәвешендә бирелә.

Гаризаны электрон рәвештә тутырганда мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

кулланучының теләге буенча электрон формага кертелгән мәгълүматны саклап калу, шул исәптән, электрон формага кабат кертү өчен кертүдә һәм кире кайтаруда хаталар барлыкка килгән очракта да;

ЕСИА да урнаштырылган мәгълүматлардан һәм Республика порталында бастырылган мәгълүматлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан электрон формадагы кырларны, ЕСИА да булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә, тутыру;

элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча теләсә кайсы этапка кайту мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүченең Республика порталында элек бирелгән запросларга керү мөмкинлеге бар.

Гариза бирүченең шәхесе теркәлгән вакытта активлаштырылган булса, гаризаны җибәргәндә гади электрон култамга кулланыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба - язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге аша тормышка ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә кабул итү өчен теләсә нинди иректе датага һәм вакытка МФЦда билгеләнгән кабул итү графигы кысаларында язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу шушы датага кадәр бер тәүлек эчендә тәмамлана.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратып алына торган мәгълүматларны, шул исәптән, түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булганда);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләге буенча);

кабул итү көне һәм вакыты.

Мөрәҗәгать итүче хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче биргән документларга туры килмәү очрагында, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә раслау мөмкинлеге-талон бирелә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә мәҗбүри рәвештә, кабул итү вакытыннан 15 минут узгач, алдан язылуның юкка чыгуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итүгә вакыт интервалын исәпләү өчен кирәк булган мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр сорауны таләп итү тыела.»;

3 нче бүлектә:

Бүлекнең атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләр) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре».

Бүлекне түбәндәге пункт белән тулыландырырга:

«3.8. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре.

3.8.1. КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3)дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны Комитетка җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче КФҮләргә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, бирелә торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка сораулар

буенча хәбәр итә һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ сайтыннан ( http://mfc16.tatarstan.ru/)ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, бирелә торган документларның формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре турында мәгълүмат.

3.8.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша КФҮкә дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны тапшыра.

Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре, КФҮ эше Регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше Регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.4. Гаризаны Комитетка җибәрү.

КФҮ хезмәткәрекабул ителгән һәм теркәлгән документларны Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет һәм КФҮ арасында эш хезмәттәшлек килешүе нигезендә, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр белән-КФҮ эше Регламенты нигезендә җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮ эше регламентында, Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турындагы килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин КФҮтә гариза теркәлгән көннән килгән эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе булып, Комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар тора.

3.8.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе артыннан КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә электрон документ нөсхәсе рәвешендә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен кәгазьдә бирә. Мөрәҗәгать итүченең соравы буенча, электрон документ нөсхәсе белән бергә, аңа электрон документ алынма иягә язу юлы белән бирелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүченең килү көнендә КФҮ эше Регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.»;

6 бүлек үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентның белешмә өчен кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда («Аеруча

саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның 3[1] статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш), төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазен җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта ( белешмә өчен)»

Форма

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аны башкаруны тикшерүче вазыйфаи затларның реквизитлары

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электронный адрес |
|---|---|---|
| Комитет рәисе | 211-66-47 | ojm@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | 211-75-06 | Ramil.Sharafutdinov0@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | 211-70-78 | Rinat.Chispyakov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | 211-68-62 | Roza.Ahmetsafina@tatar.ru |

**Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |